СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫ ИҖТИМАГЫЙ - СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА.

22 ФЕВРАЛЬ, 1997 ел. ШИМБӘ

Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга. | № 21 (8033) | Бәясе билгеләнгәнчә.

**Яз ишек кага**

## Эшне тиз тоттылар

Безнең Югары Норлат авылы халкы - оешкан, эшчән халык. Тапшырылган эшне җиренә җиткереп үтәү - безнең өчен закон. Әле менә узган ел көзге кыр эшләреннән соң барлык техниканы, авыл хуҗалыгы машиналарын кышкы саклауга кую чорында да бөтен халык мастерскойда булды. Аннан бердәм төстә ремонт эшенә керештеләр. Бездә бит механизаторларның һәркайсына диярлек берьюлы берничә төрле техника беркетелгән. Аңлашыла ки, аларның саклanышы өчен дә үзләре үк җаваплы алар. Шуңа да техниканы саклауга куюга ук аны ремонтлауга керештеләр механизаторлар. Чөгендер игү буенча механикалаштырылган звено җитәкчеләре Шамил Яруллин һәм Зәйдулла Мөхәммәтов үз карамакларындагы Т - 70 тракторларын төзәттеләр башта. Һәр узелын энә күзеннән үткәрделәр, карадылар, майладылар. Хәер, бу механизаторлар өчен күрсәтмә дә, артларыннан контроль дә таләп ителми. Алар һәр эшне үзләре белеп эшлиләр, ә инде техникага сак караштa булулары турында әйтәсе дә юк. Шуңа техникалары да ышанычлы аларның.

Гомумән, бездә мондый механизаторлар байтак. Әнә, Ирек Гыйльманов, Нәфис Бикбаев, Солтангәрәй Мөхәммәтов, Шәмсетдин Мусин быел үз карамакларындагы техникаларын тиз арада төзәтеп бетерделәр дә, авыл хуҗалыгы машиналарын ремонтлауга керештеләр. Шөкер, бу эшне дә тиз тоттылар алар. Бүгенге көнгә хуҗалыктагы тракторларның 70 проценты, авыл хуҗалыгы машиналарының бөтенесе диярлек сафта икән, бу алда телгә алынган механизаторларның кыш буе тырышып эшләүләре нәтиҗәсе булып тора. Билгеле инде, эшләрендә кыенлыклар да аз булмады. Һәркайдагыча алар да запас частьләр җитмәүдән иза чиктеләр. Дөрес, инженерлык хезмәткәрләре дә кул кушырып утырмадылар: запас частьләр табыштырдылар, искеләрен реставрацияләштеләр.

Ин мөһиме, безнең авыл механизаторлары язны тулы хәзерлек белән каршылыйлар. Бу - хуҗалыкның язгы кыр эшләренә оешканлык белән керешәчәгенә өметне ныгыта.

**Г.ТӨХФӘТУЛЛИНА.**
**Югары Норлат авылы.**

*Хезмәтләре белән мактаулылар*



Евгений Тимофеевич Мандрейкинның «Сельхозтехника» район берләшмәсенә эшкә килүенә 15 елдан артык инде. Ул слесарь булып эшли. Евгений Тимофеевич авыл хуҗалыгы машиналары өчен сошниклар ремонтлау буенча специальләшкән. Берләшмәдә эшләү чорында аның кулы аркылы күпме сошник узуын санап чыгару да мөмкин түгелдер инде, мөгаен. Мандрейкин исә үз эшенә һәрчак зур җаваплылык белән карый. Сыйфат аның өчен һәрчак беренче планда.

**Рәсемдә: слесарь Е.Т.Мандрейкин.**

Н.АЗИЗОВ **фотосы.**

## Котлыйбыз!

Авыл хуҗалыгы өлкәсендәге уңышлары өчен «Норлат - Октябрь элеваторы» акционерлык җәмгыяте генераль директоры **Әхмәтнәкыйп Нурми улы Минһаҗевка «Татарстан Республикасының атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

**23 февраль - Ватанны саклаучылар көне**



Район хәрби комиссары подполковник **Фәргать Әүхәтович САДРИЕВ:**

## «Ватанны саклау изге бурыч булып кала»

**Бәйрәм алдыннан безнең корреспондентыбыз Ф.Ә.Садриев белән сөйләшеп, аңа берничә сорау бирде.**

**- Фәргать Әүхәтович, Ватанны саклаучылар көне уңаеннан редакция коллективы һәм укучылар исеменнән котлаулар кабул итегез.**

- Рәхмәт.

**- Бу көн сезнең өчен ни дәрәҗәдә якын?**

- Мин - офицер, армиягә 20 ел гомеремне бирдем. Бу көнне безнең армиябез һәм флотыбызга хезмәт итүче хәрбиләрнең вакыт тарафыннан яңартылган профессиональ бәйрәме дип саныйм. Алай гына да түгел. 23 февраль - беркем тарафыннан да сызып ташлана алмый торган бәйрәм, илебезне, Ватаныбызны саклаучы Армия туган көн. Ватанны саклаучы... Россиядә бу сүз һәрчак горур яңгырады. Ары таба да шулай булырга тиеш, шулай булыр да - үз Ватанына начарлык теләргә мөмкинме?

**- Әмма, килешегез, бу бәйрәм ореолы барыбер бераз тонықланды...**

- Сез аны без яшәгән вакыт белән бәйлисезме? Әйе, халыкта ничә дистә еллар яшәгән гомуммилли идея ил «руле» артында торучыларда да юылган, Россия мәнфәгатьләрен ачык һәм төгәл аңлау юк. Дәүләтнең армиягә битараф карашы нәкъ шуннан килә, чөнки нәкъ ул Ватанның калканы бит. Бердәнбер һәм иң мөһим калканы. Бу - чит түгел, безнең армиябез, аңа булышырга, ашатырга - эчертергә, ахыр чиктә аңа ышанырга кирәк. Ә бу көн барыбер безнең белән кала, чөнки бу календарьдагы чираттагы «кызыл» дата түгел, ә Ватанны саклаучыга, солдатка ихтирам көне. Куликово, Бородино кырында да, Смоленск, Сталинград астында да Ватанга хезмәт итүчеләргә ихтирам көне. Әгәр бездә бу актның изгелеген аңлау яши икән, димәк, бездә өмет бар, без рухи умырткабыздан мәхрүм итүчеләргә каршы торырга сәләтлебез. Ул исә еллар дәвамында тарих тарафыннан ныгыган. Шуңа да бәйрәм алдыннан сугыш елларында Ватанны сакларга басучылар исемен зур хөрмәт белән атыйбыз. Фронтка безнең районнан гына да 12500 кеше киткән. Күп якташларыбыз - әлегә алар 89 кеше исәпләнә - 54 нче укчы гвардия дивизиясе составында хезмәт иткән. Болар - Киекледән Гыйләҗетдин Сираҗетдин улы Заһретдинов, Василий Артемьевич Анисимов (Мамык), Павел Сергеевич Ботряков (Норлат), Гаврил Егорович Ерепов (Илюткино) һәм башкалар. Аларның 72се бүген дә исән - саулар. Җиңү өчен фронтта гына түгел, тылда да көрәш барган. Шуңа да 23 февраль күпләргә, бик күпләргә кадерле...

**- Әле сугыштан соң башкалары да булды... Бәйрәм алдыннан бу сорауны бирү бәлки урынсыздыр да... Әмма Чечнядагы, Әфганстандагы хәрби хәрәкәтләр турында хатирәләр әле өр - яңа. 15 февральдә хәрби - интернационалистлар хәтер көнен билгеләп үттеләр.**

- Һәр сугышка без өнәмичә карыйбыз. Тик солдат әмерне сайлый алмый. Хезмәтендә ул командир әйткәнне үти. Безнең солдат сугышка эләккән икән, Ватанны саклаучы буларак иң күркәм сыйфатларны күрсәтә. Әйе, безнең егетләр Чечняда һәм башка «кайнар нокталарда» да хәрби хәрәкәтләрдә катнаштылар, үз бурычларын үтәделәр. Әфганлылар хакында аерым әйтәсем килә. 160лап якташыбыз Әфганда хәрби бурычларын үтәделәр. Безнең районда хәрби - әфганлыларның үз оешмасы бар, аларның да, якыннарын Әфган сугышында югалткан гаиләләрнең дә үз проблемалары байтак. Аларны бергәләшеп хәл итәргә кирәк.

(Ахыры 2 нче биттә).

**Районыбыз тормышыннан хәбәрләр**

### ТАБЫШЛЫ ЦЕХ

**Көнкүреш**

Йон теттерү цехы - халыкка хезмәт күрсәтү район производство идарәсендәге нәтиҗәле эшләүче, табышлы цехларның берсе. Биредә халыкның һичкайчан бетеп торганы юк. Август аеннан майгача биредә аеруча киеренке була. Ике дистә ел бервөзлексез монда эшләүче Әбҗәлетдин ага Шәрәфетдинов цехка мөрәҗәгать итүчеләрнең берсен дә кире борып җибәрми юк. Норма буенча бер сәгатькә 8 килограмм йон эшкәртергә тиеш булса, ул аны һәрчак арттырып үти. Узган елның августыннан быелның февраленә кадәр цех идарә касссына 20 миллион сумга якын керем бирде.

Ә. Шәрәфетдинов цехта ремонт эшләрен дә үзе үк башкара.

### КИЕЗ ИТЕКМЕ? БАР

Идарә хезмәт күрсәтү белән бергә товар да реализацияли. Аларның күп өлеше идарә цехларында җитештерелгән әйберләр булса, халык өчен бик кирәк булган кайбер товарлар, мәсәлән, киез итекләрне төрле шәһәрләрдән сатып алып, реализацияләр. Кыш салкын килү сәбәпле быел киез итекләргә ихтыяҗ аеруча зур булды. Көнкүреш хезмәте күрсәтүчеләр аның барлык үлчәмдәгеләрен дә кайтартып сату иттеләр. Киез итекләр турыдан - туры авыл комплекслы кабул итү пунктлары аркылы да сатылды.

## Игъланнар тактасы

**Бүген 17.00 сәгатьтә район культура йортында Ватанны саклаучылар көненә багышланган театрлаштырылган бәйрәм концертына чакырабыз.**

Аның программасында:
- Ватанны саклаучылар белән очрашу;
- Үзешчән сәнгатьтә катнашучы иң яхшы ансамбльләр һәм солистлар чыгышы;
- Тынлы оркестр астында бию программасы.

Концертка керү - ирекле.

## Самолет оча башлый

24 февральдән Норлат белән Казан арасында АН - 2 самолетлары яңадан оча башлый. Самолет Норлаттан һәр көнне көндезге сәгать 1 нче яртыда китә. Билет бәясе 80 мең сум. Октябрь районында пропискада торучыларга район хакимияте карары белән тарифның 50 проценты күләмендә ташлама ясала.

Белешмәләр өчен тел.: 2 - 20 - 06.

**Норлат аэропорты дирекциясе.**

## Муса Җәлил исемендәге республика бүләге булдырылды

**Татарстан Республикасы Президенты М.Ш.Шәймиев Татарстан Республикасының интеллектуаль һәм рухи потенциалын үстерү, әдәбият, сәнгать, фән һәм мәгариф өлкәсендә талантлы яшьләргә ярдәм итү, яшьләр арасында кәсәбәчелеккә булышлык күрсәтү максатында Муса Җәлил исемендәге Республика бүләген булдыру турындагы Указга кул куйды. Татарстан Республикасы законнарында каралган, һәркайсы кырык минималь хезмәт хакы күләмендә, Муса Җәлил исемендәге дүрт республика бүләге булдырылды.**

## *Мәскәүдән телеграмма*

**Хөрмәтле октябрьлеләр!**

Сезнең барчагызны Ватанны саклаучылар көне белән котлыйм. Бөек Ватан сугышы һәм хезмәт ветераннарына хөрмәтемнең аеруча олысы. Сезнең сугышчан һәм хезмәт даныгыз Ватанның киләчәк саклаучылары өчен якты үрнәк булып тора. Барчагызга да чын күңелдән тыныч күк, уңышлар, тазалык, бәхет телим.

**Хөрмәт белән**
**РФ Дәүләт Думасы депутаты А.ХАМАЕВ.**

